КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 1 сентябрь г.Казань № 742

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 июнь; 265 нче; 2005 ел, 8 сентябрь, 442 нче; 2006 ел, 30 гыйнвар, 33 нче; 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2007 ел, 5 март, 70 нче; 2008 ел, 4 февраль, 61 нче; 2009 ел, 9 сентябрь, 628 нче; 2009 ел, 18 декабрь, 860 нчы; 2013 ел, 4 март, 144 нче; 2016 ел, 20 февраль, 106 нчы; 2017 ел, 3 июнь, 335 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

24 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«халыкка гадәттән тыш хәлләр, аларның параметрлары һәм масштаблары, зарар китерә торган факторлары, халыкның һәм территорияләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар, саклау ысуллары һәм

алымнары, гамәлләр кылу тәртибе, гадәттән тыш хәл зонасында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм зыян күрүчеләрне социаль яклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары турында, шул исәптән Россия Федерациясе законнарында каралган түләүләрне алу хокукы турында, гадәттән тыш хәлләр аркасында югалган документларны яңадан рәсмиләштерү тәртибе турында мәгълүмат бирү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин